| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.03.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 710** |
|---|---|---|

2025 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 606 176,00 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 3 212 352,00 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 4 818 528,00 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 6 424 704,00 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 8 030 880,00 сум;

1.1.6.алты кешедән торган гаилә өчен – 9 637 056,00 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 11 243 232,00 сум.

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 64 846,28 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 64 846,28 сум;

1.2.3. өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 64 846,28 сум.

2. «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә кую вакытында кулланырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы

Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин